**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Яңа Кужак авылында гражданнар җыены карары**

21 март 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Яңа Кужак авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Яңа Кужак авылы гражданнары җыенының 2023 елның 9 ноябрендәге 1нче номерлы карарының 2 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:.

“2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлларны ремонтлау);

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.”.

2. Җыен нәтиҗәләрен Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Яңа Кужак авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Яңа Чәчкап авыл җирлеге башлыгы __________ Д.Д.Абдрахманова

Халык җыены секретаре __________ М.Г. Йосыпова